КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 декабрь г.Казань № 1642

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Саескан Тавы – Шәле» (I, II этаплар) төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Саескан Тавы – Шәле» (I, II этаплар) төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен «Альмера» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – алына торган кишәрлек милекчесе) милкендәге Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шәле авыл җирлеге адресы буенча урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 159 978 кв.метр мәйданлы, 16:33:170415:433 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 17 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. 16:33:170415:433 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан 16:33:170415:435 кадастр номерлы «Юл транспорты корылмалары. «Саескан Тавы - Шәле» автомобиль юлы», 16:33:170416:858 кадастр номерлы «Юл транспорты корылмалары. «Саескан Тавы - Шәле» автомобиль юлы», 16:33:000000:5915 кадастр

номерлы «Юл транспорты корылмалары. «Саескан Тавы - Шәле» автомобиль юлы» капиталь төзелеш объектлары тартып алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Саескан Тавы – Шәле» (I, II этаплар) төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документларын раслау турында» 2023 елның 19 октябрендәге 269 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты нигезендә 16:33:170415:433 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм тартып алынган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен уздыруны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин